# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

“31” гыйнвар 2018 ел Яр Чаллы № 180

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районындагы җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы; “Җирләү һәм җирләү эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законы; “Татарстан Республикасының күмү һәм җирләү эше турында”, “Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 гыйнварындагы 74 номерлы “2018 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында”гы карарлар нигезендә,

**карар бирә:**

1. 2018 елның 1 февраленнән, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә, Тукай муниципаль районының Башкарма комитетының карары (1 нче һәм 2 нче кушымта) нигезендә, хезмәтләр бәясен 5701,31 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының “Тукай муниципаль районындагы җирләү хезмәтләре кыйммәтен раслау турында” 2017 елның 31 гыйнварындагы 201/1 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар буенча рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет житәкчесе Ф. М. Камаев